## Май аенда кояш чыгу, кояш бату һәм намаз уку вакытлары

| Көннәр | Иртәнге намаз | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Кояш бата Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 3.36 | 5.06 | 13.05 | 17.45 | 20.11 | 21.41 |
| 2 | 3.34 | 5.04 | 13.05 | 17.46 | 20.13 | 21.43 |
| 3 | 3.32 | 5.02 | 13.05 | 17.48 | 20.14 | 21.44 |
| 4 | 3.30 | 5.00 | 13.05 | 17.49 | 20.16 | 21.46 |
| 5 | 3.28 | 4.58 | 13.05 | 17.50 | 20.18 | 21.48 |
| 6 | 3.26 | 4.56 | 13.05 | 17.51 | 20.20 | 21.50 |
| 7 | 3.24 | 4.54 | 13.05 | 17.52 | 20.21 | 21.51 |
| 8 | 3.23 | 4.53 | 13.05 | 17.53 | 20.23 | 21.53 |
| 9 | 3.21 | 4.51 | 13.05 | 17.54 | 20.25 | 21.55 |
| 10 | 3.19 | 4.49 | 13.05 | 17.55 | 20.26 | 21.56 |
| 11 | 3.17 | 4.47 | 13.05 | 17.56 | 20.28 | 21.58 |
| 12 | 3.15 | 4.45 | 13.05 | 17.57 | 20.30 | 22.00 |
| 13 | 3.14 | 4.44 | 13.05 | 17.58 | 20.31 | 22.01 |
| 14 | 3.12 | 4.42 | 13.05 | 17.59 | 20.33 | 22.03 |
| 15 | 3.10 | 4.40 | 13.05 | 18.00 | 20.35 | 22.05 |
| 16 | 3.09 | 4.39 | 13.05 | 18.01 | 20.36 | 22.06 |
| 17 | 3.07 | 4.37 | 13.05 | 18.02 | 20.38 | 22.08 |
| 18 | 3.06 | 4.36 | 13.05 | 18.02 | 20.40 | 22.10 |
| 19 | 3.04 | 4.34 | 13.05 | 18.03 | 20.41 | 22.11 |
| 20 | 3.03 | 4.33 | 13.05 | 18.04 | 20.43 | 22.13 |
| 21 | 3.01 | 4.31 | 13.05 | 18.05 | 20.44 | 22.14 |
| 22 | 3.00 | 4.30 | 13.05 | 18.06 | 20.46 | 22.16 |
| 23 | 2.59 | 4.29 | 13.05 | 18.07 | 20.47 | 22.17 |
| 24 | 2.57 | 4.27 | 13.05 | 18.08 | 20.49 | 22.19 |
| 25 | 2.56 | 4.26 | 13.05 | 18.08 | 20.50 | 22.20 |
| 26 | 2.55 | 4.25 | 13.05 | 18.09 | 20.51 | 22.21 |
| 27 | 2.54 | 4.24 | 13.05 | 18.10 | 20.53 | 22.23 |
| 28 | 2.52 | 4.22 | 13.05 | 18.11 | 20.54 | 22.24 |
| 29 | 2.51 | 4.21 | 13.05 | 18.12 | 20.55 | 22.25 |
| 30 | 2.50 | 4.20 | 13.05 | 18.12 | 20.57 | 22.27 |
| 31 | 2.49 | 4.19 | 13.05 | 18.13 | 20.58 | 22.28 |

*Намаз вакытлары турында мәгълүматларны Самара өлкәсе мөселманнарының Региональ Диния нәзарәте хезмәткәрләре әзерләдә, мөфти Вагыйз хәзрәт ЯРУЛЛИН раслады. Җомга көннәре аерып күрсәтелгән.*


**Учредители: трудовой коллектив редакции газеты «Бердэмлек» и Региональное Духовное управление мусульман Самарской области.**

**Оештыручылар: «Бердәмлек» газетасы редакциясенең хезмәт коллективы һәм Самара өлкәсе мөселманнарының Региональ Диния нәзарәте.**



بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

# Кыйбла

№ 4
2012 ел
апрель

„БЕРДӘМЛЕК“ ГАЗЕТАСЫНЫҢ АЙЛЫК ДИНИ КУШЫМТАСЫ




***ВӘГАЗЬ***

# Ялган турында

Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи раббил гааләмиииин вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлинә Мөхәммәдиү үә галәә әәлиһи үә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Бөтен галәмне юктан бар итеп тәрбия кылучы Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләгә биниһая хәмед-сәнә, шөкераналарыбыз булса иде. Җәнабел Хак тарафыннан галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле әһленә, сәхабәләренә, күңел түрләребездән чыккан сәламнәребез, салаватларыбыз һәм һәртөрле изге догаларыбыз булса иде.

Мәгълүм булганча, ислам шәригате боерыклардан һәм тыюлардан тора. Бу кануннар безгә Аллаһы Тәгалә тарафыннан билгеләнгән. Фани дөньядагы һәм ахирәттәге тормыш бәхетле, тыныч, матур булсын өчен, кеше шул илаһи кануннар буенча яшәргә тиеш. Шәригатебездә тыелган гамәлләрнең берсе - ялган.

Ялган, гомумән, кешелеккә иң зур зыян китерүче гөнаһ булып тора. Ялган - ул калебне үтерүче рухи авыру. Күп вакытта кешеләр хурлыкта калмас өчен, үзләренең дәрәҗәләрен төшермәс өчен, ялган сүзләр сөйлиләр. Аның ярдәмендә кеше тыңлаучыларны ышандырырга мөмкин, ләкин, мөхтәрәм җәмәгать, барлык нәрсәне белеп торучы Раббыбыз - Аллаһы каршында җавап бирәчәгебезне онытмасак иде. Әгәр дөньяда кеше ялган сүзләр сөйләп, төрле хурлыклардан сакланса, киләсе дөньяда шулар аркасында кеше тагын да күбрәк хурлыкка төшәчәк. Дөньялыкта бәндә өч-дүрт кеше янында ялганчы булырга мөмкин, әмма Ахирәттә барча кешеләр алдында ул нишләр икән соң? Алар арасында дуслары, якын туганнары да булачак бит!

Изге Коръәндә Аллаһы Тәгалә болай дип боера: *«...Ялган сүздән сакланыгыз»* («Хаҗ» сүрәсе, 30нчы аять). *«Әй, мөэминнәр, Аллаһыдан куркыгыз! Сөйләгән вакытта чын дөресен сөйләгез»* («Әхзәб» сүрәсе, 70нче аять).

Хөрмәтле мөселманнар! Ялганчы башкаларга түгел, ә үзенә зыян китерә. Аның бөтен ялган сүзләре үзенә каршы юнәлтелгән. Кеше ялган сөйләгәндә, аңардан фәрештәләр ерагая бара. Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәләм хәзрәтләре үзенең бер хәдисендә әйткән: *«Аллаһының колы ялганны сөйләгән вакытта шушы гөнаһның җирәнгеч исеннән фәрештәләр чакрым ярым ераклыкка кача»,* - дигән (Тирмизи).

Икенчедән, ялган кешене гөнаһка китерә, аннары - җәһәннәмгә. Хәдис-шәрифтә әйтелгән: *«Ялган кешене гөнаһка, ә гөнаһ исә җәһәннәмгә илтә. Әгәр кеше даими рәвештә ялганласа, ул Аллаһы Тәгалә каршында ялганчы булып язылыр»* (Бохари, Мөслим).

Өченчедән, ялган кешенең кальбен каралта һәм хак юлда аңа киртә булып тора. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм әйтте: *«Аллаһының колы ялганлаган вакытта аның күңелендә кара тап барлыкка килә. Аннан соң бу таплар күбәя һәм калеб тулысынча шушы таплар белән каплана. Шундый кеше Аллаһы каршысында ялганчы булып языла»,* - диде (Мәлик бин Әнәс, Муватта).

Сафуан бин Сүләйм (Аллаһы Тәгалә аннан разый булса иде) дигән сәхабәдән риваять ителә: Аллаһының рәсүле галәйһиссәләмнән сорадылар: *«Йә рәсүлуллаһ, мөселман куркак булырга мөмкинме?» «Әйе, мөмкин»,* - диде Пәйгамбәребез галәйһиссәләм. *«Мөселман саран булырга мөмкинме?»* - дип сорадылар. *“Әйе, мөмкин”,* - дип җавап бирде Пәйгамбәребез галәйһиссәләм. *«Мөселман ялганчы булырга мөмкинме?»* - дип янә сорадылар. *«Юк, беркайчан була алмый»,* - диде Рәсүл Әкрам галәйһиссәләм (Мәлик бин Әнәс, Муватта, Бәйһәкый).

Бу хәдистән күренгәнчә, иман белән ялган калебтә бергә була алмыйлар. Иманлы кеше кайвакыт куркак һәм саран булса да, ялган аңа бер дә килешми, чөнки ялган мөселман сыйфаты түгел. Мөселман куркак һәм саран да булырга тиеш түгел, ләкин бу сыйфатлар ялган белән чагыштырганда андый ук куркыныч түгел. Әлбәттә, хак мөселман шушы өч сыйфаттан пакь булырга тиеш. Сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәләм: *«Сез минем беркайчан да саран, ялганчы һәм куркак булуымны күрмәссез»,* - дигән (Бохари).

Тугры хәлифәләрнең берсе Гомәр бин Хәттаб (Аллаһы Тәгалә аннан разый булса иде) әйткән: *«Сез иманлы кешенең ялганчы*